# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 25 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12; Ватаным Татарстан, 2011, 5 август, 23 ноябрь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 41 статьяда:

а) икенче абзацта "10 процентын" сүзләрен "20 процентын" сүзләренә алмаштырырга;

б) өченче абзацта "муниципаль районнар" сүзләреннән соң "һәм шәһәр округлары" сүзләрен өстәргә;

2) $55^2$ статьяда:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Татарстан Республикасы Юллар фонды – гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген, шулай ук торак пунктларның күпфатирлы йортларының ишегалды территорияләрен, күпфатирлы йортларының ишегалды территорияләренә килү юлларын капиталь ремонтлауны һәм ремонтлауны финанс белән тәэмин итү максатларында файдаланылырга тиешле Татарстан Республикасы бюджеты чаралары өлеше.";

б) 2 пунктта:

беренче абзацта "Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең" сүзләрен "Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджеты керемнәренең" сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта "региональ яисә муниципальара әһәмиятле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына карата" сүзләрен төшереп калдырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

"5. Татарстан Республикасы Юллар фонды бюджет ассигнованиеләрен булдыру һәм куллану тәртибе региональ яисә муниципальара әһәмиятле гомуми файдаланудагы каты өслекле автомобиль юлларын проектлауга һәм төзүгә (реконструкцияләүгә), шулай ук гомуми файдаланудагы автомобиль юллары челтәре белән ел әйләнәсендә элемтәсе булмаган авыл торак пунктларына кадәр җирле әһәмиятле гомуми файдаланудагы каты өслекле автомобиль юлларын проектлауга һәм төзүгә (реконструкцияләүгә) җирле бюджетларга Татарстан Республикасы Юллар фонды бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләменнән кимендә 5 процент күләмендә субсидияләр бирүгә бюджет ассигнованиеләрен юнәлдерүне күз алдында тотарга тиеш.";

г) түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

"6. Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын (федераль әһәмиятле автомобиль юлларыннан гайре) төзүгә (реконструкцияләүгә), аларга капиталь ремонт ясауга, ремонт ясауга һәм аларны карап тотуга Татарстан Республикасы тарафыннан федераль бюджеттан алынган бюджет кредитлары буенча бурычны каплауга һәм шушы кредитларны файдалануга бәйле рәвештә бурыч йөкләмәләренә хезмәт күрсәтү чыгымнарын башкаруга Татарстан Республикасы Юллар фонды бюджет ассигнованиеләренең күрсәтелгән закон белән каралган күләменнән 20 процenттан артмаган күләмдә, шулай ук җирле әһәмиятле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзүгә (реконструкцияләүгә), аларга капиталь ремонт ясауга, ремонт ясауга һәм аларны карап тотуга, шул исәптән муниципаль юллар фондларын булдыруга, Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бюджет кредитлары һәм субсидияләр бирүгә Татарстан Республикасы Юллар фонды бюджет ассигнованиеләре каралырга мөмкин.".

**2 статья**

"Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында" 2009 елның 4 июлендәге 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 өлештә "2013" саннарын "2017" саннарына алмаштырырга;

2) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3. 2017 елның 1 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы эчке дәүләт бурычының (муниципаль бурычның) иң чик күләме Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 31 статьясындагы 2 һәм 3 пунктларында билгеләнгән чикләүләрдән агымдагы елның 1 гыйнварына бюджет кредитлары буенча Татарстан Республикасы дәүләт бурычы (муниципаль бурыч) күләме чикләрендә һәм (яисә) Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Татарстан Республикасы бюджетына (җирле бюджетка) агымдагы финанс елында җәлеп ителә торган бюджет кредитлары Татарстан Республикасы бюджеты (җирле бюджет) кытлыгын финанслау чыганаклары составында бюджет турында Татарстан Республикасы законы (муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы муниципаль хокукый акты) белән расланган очракта әлеге бюджет кредитлары чикләрендә артып китәргә мөмкин. 2017 елның 1 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы эчке дәүләт бурычының, шулай ук муниципаль бурычның иң чик күләме әлеге өлештә күрсәтелгән шартларны үтәгән килеш билгеләнә.".

**3 статья**

1. Әлеге Закон 2011 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктындагы "а" пунктчасының гамәлдә булуы 2012 елга, 2013 һәм 2014 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын төзегәндә барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2011 елның 30 ноябре
№ 95-ТРЗ